**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИККОЛ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 23 «22» июль 2020 ел

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикколавыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең саны һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең саны һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга (1нче кушымта).
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм авыл җирлеге территориясендә мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар басылып чыккан яисә халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Әхмәтшина

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Башкарма комитетының 22.07.2020 ел, 23 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең саны һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм аларның хезмәте өчен түләү буенча факттагы чыгымнарны (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару (ел саен) процедурасын билгели.

## II. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары турында белешмәләр тапшыру тәртибе һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны һәм хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы факттагы чыгымнары, шулай ук хисап чорында хезмәт өчен түләү чыгымнарын (акчалата тоту) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга факттагы бюджет ассигнованиеләре күләме турында квартал саен мәгълүматны (арта баручы нәтиҗә белән) чагылдыралар.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, форма буенча тапшырыла.

2.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча мәгълүмат формалаштыра.

## III. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматларны бастырып чыгару тәртибе

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча Башкарма комитетның мәгълүматларны раслау турында карары проектын әзерли.

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган хисаптан соң килә торган икенче айның соңгы числосына кадәр мәгълүматлар Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/басылып чыгарга тиеш.

3.3.Авыл җирлеге башкарма комитеты карары проектын әзерләү һәм карар белән расланган мәгълүматларны бастырып чыгару Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече тарафыннан башкарыла

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал мәгълүматларын бастырып чыгару тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында белешмәләр**

**20 ______ елның ____________кварталы**

хисап чоры (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында исемлек буенча хезмәткәрләрнең уртача саны, кеше. | Хисап чорында хезмәткәрләр өчен түләүнең факттагы чыгымнары, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре һәм аларның хезмәте өчен түләүнең факттагы чыгымнары | | |
| шул исәптән:<br>муниципаль хезмәткәрләр | | |